ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Арча муниципаль районы
Арча муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча шәһәре, мәйдан Советы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Арча шәһәре муниципаль берәмлеге
Арча муниципаль райоы
Арча шәһәре Советы
422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27
тел. 3-15-25, 3-16-25

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

23 сентябрь 2020 ел № 7

**Арча шәһәр Советының 2018 елның 4 маендагы 91 номерлы «Татартсан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында” карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасының 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы кодексы, "Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында" 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең айлык акчалата түләүләре күләмен арттыру турында" карары, «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру турында" 2020 елның 5 августындагы 655 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 2018 елның 4 маендагы 91 номерлы « Татартсан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең һәм аерым

хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү күләмнәре һәм шартлары турында" карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) Муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларга хезмәт өчен түләү турында Нигезләмәнең 3 абзацын (1 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затның хезмәте өчен түләү акчалата түләү рәвешендә башкарыла.

| Вазыйфа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
| --- | --- |
| Татартсан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегенең башлыгы урынбасары | 17062 |

2) Татартсан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларның хезмәт хакы турында Нигезләмәнең 16 абзацында (2 нче кушымта) "11 163 сум" сүзләрен "11 498 сум" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Арча муниципаль районы рәсми сайтынында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г.Нуриев